СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

20 октябрь 2025 ел

г.Мензелинск

№ 4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 20.06.2011 № 9 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру турында Нигезләмә» не раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 12.12.2023 № 594-ФЗ «Россия Федерациясенең дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 нче маддәсенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы, Россия Федерациясенең 31.07.2020 № 268-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы, Россия Федерациясенең 01.04.2019 № 48-ФЗ «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 20.06.2011 № 9 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру турында Нигезләмә»не раслау турында карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.6 пунктында «Мәгълүматләр» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2.5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны;

1.3. 1 нче Кушымтаның 2.5 пунктындагы 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне» сүзләрен өстәргә;

1.4. 1 нче кушымтаның 2.5 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ рәвешендә теркәлүне раслый торган документ;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе А. Ф. Сәлахов